| «Каралды» Башлангыч сыйныф укытучыларының ММБ җитәкчесе ________/ Идрисова Г.Ф./ Беркетмә № 1 «_28_» август 2021 ел | «Килешенде» «Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе»ГББМБУнең укыт эшләре буенча директор урынбасары ________/Гараева С.Р../ «28 » август 2021ел | « Утверждаю» «Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе» ГББМБУ директоры ________/Гайнуллин З.А./ Приказ № 87 «31» август 2021ел |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле урта гомуми белеем бирү мәктәбе

Башлангыч сыйныфларда белем бирү өчен
**“Туган тел (Татар теле)”**
**предметыннан эш программасы**
( реализации вакыты - 5 ел)

**Педагогик совет киңәшмәсендә**
**каралды һәм кабул ителде**
**Беркетмә № 1**
**«28» август 2021 ел**

**Төзүчеләр: башлангыч сыйныф укытучылары**
**Зиятдинова Ф.Г**
**Идрисова Г.Ф.**

**УКУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУНЫҢ КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘРЕ**
**1класс**

| **Бүлекләр** | Универсаль уку гамәлләре | | | Шәхескә кагылышлы |
|---|---|---|---|---|
| | Танып белү | Коммуникатив | Регулятив | |
| **Грамота га өйрәтү. Әзерлек чоры .** | Дәреслектә ориентлаша белү; шартлы билгеләрнең телен белү; рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү; кирәкле мәгълүматны аерып ала белү. | Укытучыны,иптәшеңне тыңлый һәм ишетә белү; күршең белән хезмәттәшлек итү. | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу; гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау; | Мәктәпкә уңай караш; яңа белемнәр алырга омтылыш; бергәләп уку эшчәнлегендә активлык күрсәтү; дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү; |
| **Әлифба чоры** | Дәреслектә ориентлаша белү; шартлы билгеләрнең телен белү; рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү; төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру; | Укытучыны,иптәшеңне тыңлый һәм ишетә белү; Иптәшеңнең позициясен истә тотып, аңа аңлаешлы итеп сөйләү; күршең белән хезмәттәшлек итү; төркемдә эшли белү. | Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү; эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен критерийлар буенча билгеләү. | Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү; үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү; үз мөмкинлекләреңне бәяләү; үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру; мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую) |
| **Әлифба дан соңгы чор** | Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү; | Тормыш тәҗрибәсен куллану; күршең белән хезмәттәшлек итү. | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу; гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | төмамлау; | |
| **Җөмлә . Җөмлә ахырында тыныш билгеләре.** | Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү; | Тормыш тәҗрибәсен куллану;<br><br>күршең белән хезмәттәшлек итү. | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм төмамлау; | Мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую) |
| **Сүзләр.** | Төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;<br>чагыштыру, төркемнәргә аеруны формалаштыру;<br>эзләргә, кирәкле мәгълүматны табарга тырышлыкны формалаштыру:<br>дидактик рәсемле язуларны дөрес итеп сайлап табып уку | Укытучыны,иптәшеңне тыңлый һәм ишетә белү;<br>Иптәшеңнең позициясен истә тотып,аңа аңлаешлы итеп сөйләү;<br>күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>төркемдә эшли белү. | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br><br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм төмамлау; | Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>үз уңышларың/ уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>үз мөмкинлекләреңне бәяләү; |
| **Телдән һәм язма сөйләм серләре** | Телдән һәм язма сөйләмне аера белүләре, аларның уртак һәм аермалы якларын табулары;<br>3 охшаган вариантның кирәклесен аерып ала белүләре;<br>шартлы билгеләрнең телен белү;<br>логик басым китереп чыгарган үзгәрешләрне белүләре; | Башкаларны ишетә һәм тыңлый белү,тиешенчә җавап бирү;<br>иптәшеңнең позициясен истә тотып,аңа аңлаешлы итеп сөйләү, язу;<br>күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>укытучының һәм иптәшләренең сорауларына җавап бирә белү; | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм төмамлау;<br>үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;<br>тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>эшләнгән эшнең | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;<br><br>мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | диалогта катнашу;<br>этикет кагыйдәләрен белү; | сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү | |
| **Авазлар һәм хәрефләр** | Алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ; | Башкаларны ишетә һәм тыңлый белү,тиешенчә җавап бирү;<br>иптәшеңнең позициясен истә тотып,аңа аңлаешлы итеп сөйләү;<br>күршең белән хезмәттәшлек итү; | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау; | Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>үз уңышларын/ уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>үз мөмкинлекләреңне бәяләү; |
| **Уку елында өйрәнгән нәрне ныгыту** | Дәреслектә ориентлаша белү;<br>шартлы билгеләрнең телен белү;<br>рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;<br>кирәкле мәгълүматны аерып ала белү.<br>алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;<br>материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;<br>дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;<br>төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;<br>чагыштырыру, төркемнәргә аеруны формалаштыру;<br>эзләргә, кирәкле мәгълүматны табарга тырышлыкны формалаштыру<br>дидактик рәсемле язуларны дәрес | Башкаларны ишетә һәм тыңлый белү,тиешенчә җавап бирү;<br>иптәшеңнең позициясен истә тотып, аңа аңлаешлы итеп сөйләү;<br>күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>укытучының һәм иптәшләренең сорауларына җавап бирә белү;<br>диалогта катнашу;<br>этикет кагыйдәләрен белү; | Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;<br>үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;<br>тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү;<br>план буенча эшли белү,үзең дә план төзү | Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>үз уңышларын/ уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>үз мөмкинлекләреңне бәяләү;<br>үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;<br>мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)<br>телгә хөрмәт уяту, аның байлыкларын аңлау;<br>башкалар фикеренә уңай караш формалаштыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | итеп сайлап табып уку | | | |

| **УКУЧЫЛАРНЫҢ ӘЗЕРЛЕК ДӘРӘҖӘСЕНӘ ТАЛӘПЛӘР**<br>**Курсның көтелгән предметлы нәтиҗәләре** | |
|---|---|
| **Грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында беренче сыйныф укучылары:**<br>1. Тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны аңлый, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белергә;.<br>2. 2 — 4 сүздән торган җөмләләр һәм 3 — 4 җөмләдән торган хикәя төзи, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да дөрес яза белергә тиешләр.<br>3. Татар теленең авазларының сузык һәм тартык авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә- калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;<br>- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;<br>- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;<br>- элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын аңлый белергә тиеш.<br>4. Укучылар элемент-шаблоннар нигезендә язма хәрефләрне төзи һәм анализлый;<br>- аерым график биремне үтәү дәвамында дөрес итеп утыра һәм язма әсбаплардан файдалана ала;<br>- билгеле бер алгоритм буенча хәрәкәт элементлары нигезендә хәрефләр яза;<br>- иҗекләрдә һәм сүзләрдә тоташтыруның өч алымын үти;<br>- бизәк-бордюрлар ясый ала белергә тиешләр.<br>5. -Татар алфавиты басма һәм язма хәрефләренең график системасын;<br>- һәр хәрефнең элемент формаларын;<br>- дөрес утыру һәм язма әсбапларны куллану кагыйдәләрен белергә тиеш.<br>2. Һәр укучы үзенә генә хас темпта язма текстларны орфоэпик нормаларга туры китереп укый;<br>- сүзләрне өзмичә язу күнекмәләрен үзләштерә.Һәр укучы, шәхси мөмкинчелеген истә тотып, язу темпын арттыра белү кебек эш төрләрен башкара белергә тиеш. | **Татар теле буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**<br><br>татар графикасы үзенчәлекләрен белү;<br>сүзнең мәгънәле кисәкләрен аера белү;;<br>авазларны, сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес итеп әйтергә өйрәнү;<br>өйрәнелгән җөмлә төрләрен тиешле интонация белән әйтә белү;<br>аваз, сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес әйтү нормаларын саклау;<br>тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу.<br>укучыларның сүз байлыгын укуга һәм тормыш-көнкүрешкә бәйле сүзләр хисабына арттыру;<br>төрле типтагы сүзлекләр белән эшли белү;<br>өйрәнелгән орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләрне катлаулы булмаган язма сөйләмдә дөрес куллану; |

## 2 нче сыйныф

| Бүлек | Планлаштырылган нәтиҗәләр | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Танып белү УУГ | Регулятив УУГ | Коммуникатив УУГ | Шәхескә кагылышлы УУГ |
| **Фонетика һәм орфоэпия .** | -Дәреслектә ориентлаша белү;<br>- шартлы билгеләрнең телен белү;<br>- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;<br>- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;<br>- алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;<br>- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;<br>- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү; | -уку хезмәтендә максат кабул итү, аңа ирешү өчен этапара бурычлар кую һәм аларга ирешү өстендә эшләү;<br>-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;<br>- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;<br>- тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | - тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>- ачыклаучы сораулар бирә белә;<br>- эчтән һәм кычкырып аңлап уку;<br>- төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позицияңне нигезләү. | - мәктәпкә уңай караш;<br>-яңа белемнәр алырга омтылыш;<br>-бергәләп уку эшчәнлегендә активлык күрсәтү;<br>-төркемдә үзара ярдәм итешү, дискуссиядә катнашу;<br>- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>- үз уңышларың, уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;<br>- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | формалаштыру;<br>- тәп мораль нормаларны белү һәм аларны үтәүгә ориентлашу. |
| **Графика** | - алфавитта тамгаларның (хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;<br><br>-модельләштерү-тойгы объектның билгеләрен графика яки тамга-символик формага күчерү, шул модельне өйрәнелә торган фәннең гомуми законнарына буйсындырып үзгәртү, | -уку мәсьәләсен кабул итәргә һәм аны эш дәвамында сакларга,<br>-укытучы тарафыннан билгеләнгән эш-гамәл ориентирларын яңа уку материалында исәпкә алырга,<br>-үз эш -гамәлләреңне куелган бурычка һәм аны гамәлгә ашыру шартларында туры китереп планлаштырырга, -укытучы һәм башкаларның бәяләрен һәм тәкъдимнәрен дөрес кабул итәргә, бәя һәм ясалган хаталар характерын исәпкә алып эш-гамәлләргә кирәкле төзәтмәләр кертергә<br>- | - тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>-кешеләрдә төрле фикерләр булу мөмкинлеген кабул итәргә, хезмәттәшлек һәм аралашу партнеры позициясенә ориентлашырга, үз фикереңне һәм позицияңне формалаштырырга, уртак эшчәнлектә килешергә һәм гомуми чишелешкә килергә, партнерның нәрсәне белүен һәмкүрүен,әнәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирергә,партнерныңэш-гамәлләрен контрольгә алырга, сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә. | -укытучы һәм башкаларның бәяләрен аңлау;<br>-уку эшчәнлегенең уңышлылыгы (унышсызлылыгы) сәбәпләрен аңлау<br>- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;<br>- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;<br>- мәгънә барлыкка китерү |
| **Сүз** | -сүзнең аваз схемасын куллану, - сүзнең мәгънә кисәкләрен билгеләү һәм башка шундый эшләр тамга-символик уку гамәлләре булдырырга ярдәм итү; | -кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;<br>- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген | - тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>- эчтән һәм кычкырып аңлап уку; | - үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру - дәреслек геройларына, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | -модельләштерү-тойгы объектның билгеләрен графика яки тамга-символик формага күчерү, шул модельне өйрәнелә торган фәннең гомуми законнарына буйсындырып үзгәртү,<br>-өйрәнгән теманы схема, сызым, план формасында күрсәтү<br>-чагыштыру, гомумиләштерү, классификацияләү,абстрактлаштыру ;<br>-уку мәсәләләрен чишү өчен модель һәм схемаларны үзгәртеп корырга<br>-конкрет шартлардан чыгып, уку мәсьәләләрен нәтиҗәле чишү ысулларын сайлап алырга, җитешмәгән компонентларны тулыландырып һәм өстәп, аерым кисәкләрдән бербөтен төзеп синтезларга;<br>- бирелгән критерийлар буенча чагыштырырга, сериацияләргә һәм классификацияләргә, мәсьәләне чишү алымнарын үзләштерергә | тикшерү;<br>- тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | -партнерның эш-гамәлләрен контрольгә алырга, сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә. | күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;<br>- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;<br>- мәгънә барлыкка китерү |
| **Җөмлә** | -җөмлә кисәкләренең астына сызу,<br>сүзнең - шартлы билгеләрнең телен белү;<br>- төп билгеләрне аерып алу | -кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;<br>- тормыш тәҗрибәсен куллану; | - тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>- төрле фикерләрне исәпкә алу | - төп мораль нормаларны белү һәм аларны үтәүгә ориентлашу;<br>- дәреслек |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | нигезендә кагыйдә формалаштыру<br>- фикерләүдә логик чылбыр төзү<br>- рәсем, схемалар кулланып биремнәр үтәү | - эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | һәм үз позициянне нигезләү;<br>-кешеләрдә төрле фикерләр булу мөмкинлеген кабул итәргә, хезмәттәшлек һәм аралашу партнеры позициясенә ориентлашырга, үз фикереңне һәм позициянне формалаштырырга, уртак эшчәнлектә килешергә һәм гомуми чишелешкә килергә, партнерның нәрсәне белүен һәм күрүен, ә нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирергә, партнерның эш-гамәлләрен контрольгә алырга, сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә | геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>- үз уңышларың-уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру. |
| **Бәйләнешле сөйләм.** | - материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;<br>- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;<br>- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге шартлы билгеләрне туры китерү. | - гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;<br>- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;<br>- тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. | - төрле фикерләрне исәпкә алу һәм үз позициянне нигезләү.- тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү.<br>- аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирергә, партнерның эш-гамәлләрен контрольгә алырга, сөйләмнең диалог формасын үзләштерергә | - дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;<br>- үз уңышларың-уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;<br>- үз мөмкинлекләреңне бәяләү; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | - үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;<br>- мәгънә барлыкка китерү |

**3 нче сыйныф**

| Бүлек исеме | Предмет | |
|---|---|---|
| | Укучыда формалашачак | Формалашу өчен укучы алачак мөмкинлекләр |
| Фонетика, орфоэпия һәм графика | – аваз һәм хәрефләрне аера;<br>– ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала;<br>– хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала. | - укучыга дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча сүзгә мөстәкыйль рәвештә фонетик-график (аваз-хәреф) анализ ясарга өйрәнү, сүзгә ясалган фонетик-графиканализныңдөреслегенбәяләү мөмкинлеге бирелә.<br>– үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклыйһәмеңгәмәдәшененңсөйләмендәбу нормаларның дәреслектә бирелгән материал күләмендә үтәлүен бәяли;<br>– сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала. |
| Лексикология | - мәгънәсе ачыклану таләп ителә торган сүзләрне табарга;<br>– текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә. | - укучы, текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге ала. |
| Сүз төзелеше (морфемика) | – тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга;<br>– сүзнең тамыр һәм кушымчаларын | - укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларның чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген |

| | | |
|---|---|---|
| | (аффиксларын) табарга өйрәнә. | бәяләү мөмкинлеге ала. |
| Морфология | – исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен;<br>– сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен;<br>– фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә. | - укучы дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дәреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала. |
| Синтаксис | – җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга;<br>– сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга;<br>– җөмләнең әйтү максаты буенча төрен аерырга;<br>– җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә;<br>тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә. | - укучы җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең дәреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала. |
| Орфография һәм пунктуация | – дөрес язылыш кагыйдәләрен өйрәнгән күләмдә кулланырга;<br>– сүзләрнең дөрес язылышын орфографик сүзлек буенча ачыкларга;<br>– 55-60 сүзле текстны дөрес итеп күчереп язарга;<br>– өйрәнелгән дөрес язу кагыйдәләренә туры килгән 50-55 сүзле текстны укытучы әйтеп торганда язарга;<br>– үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстны тикшерергә, орфографик һәм пунктуацион хаталарны табарга һәм төзәтергә өйрәнә. | - укучы орфографик хата ясау мөмкинлеге булган очракларны аңлау, аерым орфограммаларга мисаллар сайлау,текстлартөзегәндәорфографикһәм пунктуацион хаталарны булдырмау өчен, язганнарны үзгәртү, хаталар өстендә эшләгәндә, аларның сәбәпләренә төшенү һәм алдагы язма эшләрдә хата җибәрмәү юлларын ачыклау мөмкинлеге ала. |

| | | |
|---|---|---|
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | – аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга;<br>– көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес кулланырга;<br>– аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә;<br>– текстка исем бирергә;<br>– укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә;<br>– аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбриклӛү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә. | -укучы тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү, сөйләмнең сурәтләү, хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзү, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерү һәм төзәтү, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын табу, хаталы текстларга төзәтмә кертү, төрле төрдәге изложение яки сочинение язганда, эшне эзлекле алып бару, аны тикшерү һәм бирелгән үрнәк белән чагыштыру, уку бурычларының дөреслеген бәяләү, үз текстын, аралашу максаты һәм шартыннан чыгып, чыганак (беренчел) текст белән чагыштыру, электрон чыганаклардан файдаланганда, тел нормаларының үтелешен саклау мөмкинлеге ала. |

**4нче сыйныф**

**Шәхси үсеш-үзгәреш нәтиҗәләре:**

1.Уңай мотив тудыру. Уку телəге булдыру, мәктәп һәм уку эшчәнлеге турында уңай күзаллау булдыру.Мәктәпкә уңай мөнәсәбәтле укучы карашы формалаштыру..

2.Яхшы укучы образын кабул итү, яхшы укучы булу теләге тудыру.

3.Үз фикереңне җиткерү.Үз фикереңне яклый, дәлилли белү. башкаларны тыңлый белү, иптәшләрең фикере белән исәпләшү. Кеше фикеренә карата ихтирамлы караш булдыру. Кеше чыгышына игътибарлы булу.

4.Үз гаиләңә карата уңай караш, ихтирам тәрбияләү. Туганлык кыйммәте формалаштыру.

4.Тәрбияле бала образын кабул итү.Әхлак нормаларын үзләштерү.Әхлакый сыйфатлр формалаштыру.

5. Туган якка мәхәббәт хисе формалашу. Үзеңнең этник катламга мөнәсәбәтле булуыңны аңлау. Милләтнең, Ватанның бер вәкиле булуың белән горурлану.Милли үзаң булдыру. Толерантлык хисе булдыру.Горурлык һәм гражданлык хисләре формалаштыру.

6.Сәламәт яшәү рәвешен, ярдәмчел бала образын кабул итү.

7. Үзбәяләү.Уңышлы уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә үзбәя.

**Предметара нәтиҗәләр** булып универсаль уку гамәлләре формалашу санала. Грамотага өйрәтү курсын үзләштергәндә формалашучы универсаль уку гамәлләре: регулятив универсаль уку гамәлләре , танып-белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре

**Предметара нәтиҗәләр:**

1.Дәреслек битләрендә ориентлашу. Уку мәсьәләсен куя белү,аңлау һәм үтәү.Уку хезмәтенә максат кабул итү, аңа ирешү өчен этапара бурычлар кую. Укытучы бәялəвен уңай кабул итү,үзэшчәнлекне планлаштыру. Төрле ситуациядән чыгу юлларын табу.Уку эшчәнлеген оештыру.
2.Эстетик һәм рухи кыйммәтләр тупларга омтылу. Тиешле мәгълүматны таба белү.Тамга-символлик уку гамәлләрен үзләштерү.
3.Сорау кую һәм аларга җавап бирү; аралашу-сөйләм эшчәнлеген формалаштыра белү; тире-яктагылар белән аралашу ысулларын үзләштерү, иптәшләрең белән хезмәттәшлек итү, күршеңне тыңлый белү.Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. Мәгълүмат белән эшләү культурасын формалаштыру.Дөрес һәм аңлап уку күнекмәләре булдыру.

**Укыту предметының эчтәлеге**

1класс

| | |
|---|---|
| **Язарга өйрәтү өч этаптан тора.**<br>**Әзерлек чоры - Язу (10 сәг.)**<br>График системаның структур берәмлекләре, яки татар алфавитының язма хәрефләре элементлары белән танышу.<br>Язганда дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану кагыйдәләре белән танышу. Дәфтәр битләрендә ориентлашу, андагы сызыклар, вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.<br>Алгоритм буенча элемент-сызыкларны язу. Язма хәрефләрнең өлге формалары белән танышу. Бордюр-бизәкләр ясау процессында язма хәреф элементлары турында күзаллау тудыру.<br>**Әлифба чоры - Язу (51 сәг.)**<br>Язарга өйрәнүнең төп этабында (ул әлифба чорына туры килә) балалар барлык язма хәрефләрне иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә кушып (тоташ) язу күнекмәләрен алалар.<br>.Дөрес утыру һәм язу әсбапларын дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.<br>Элемент-өлгеләр ярдәмендә басма хәрефләрне төзү күнегүләре. Балалар хәтерендә барлык басма хәрефләрнең күрмә образларын формалаштыру. Элемент-өлгеләрдән язма хәрефләр төзү һәм анализлау. Гомуми уртак элемент формалары буенча хәрефләрне төркемләү һәм чагыштыру буенча логик биремнәр үтәү.<br>Балалар хәтерендә язма баш һәм юл хәрефләренең төгәл күрмә-хәрәкәтле образларын формалаштыру. Бу хәрефләрне алгоритм һәм тактлап (санап) язу технологиясен камилләштерү. | **Җөмлә . Җөмлә ахырында тыныш билгеләре (2сәгать)**<br>Җөмлә турында беренче төшенчә.Сүзләр белән җөмләләрне чагыштыру.Төрле тавыш белән әйтелгән җөмләләрдән соң куела торган тыныш билгеләре.<br>**Сүзләр. ( 3 сәгать)**<br>**Предмет** атамасын белдергән сүзләр – исемнәр белән таныштыру. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү; уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның дөрес язылышы. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр – бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән таныштыру.<br>Предметның **билгесен белдергән** сүзләр белән таныштыру**Эш-хәрәкәтне** белдергән сүзләр – фигыльләр белән таныштыру**.**<br>**Телдән һәм язма сөйләм серләре (5 сәгать)**<br>Телдән сөйләмнең үзенчәлекләре (интонация, сүз басымы). Язма сөйләм үзенчәлекләре (җөмлә башында, ялгызлык исемнәрдә баш хәреф). Анда сүзнең кем? Нәрсә? турында баруын һәм алар хакында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләр. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү. Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре.Өзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү. Аерым темалар буенча өйрәнгән |

| | |
|---|---|
| Язуда оч төрле (өске, урта-йөзмә, аскы) тоташтыру алымы белән танышу.Дәрестә өйрәнелә торган хәрефне элек өйрәнелгән хәрефләр белән тоташтыру алгоритмнарын үзләштерү.<br>Сүзнең аваз схемасын график формага үзгәртү һәм алга таба язма хәрефләр белән язу. Язма хәрефләр белән бирелгән иҗек, сүз, җөмлә үрнәкләрен уку, үрнәк буенча язу. Укучыларның үз язуларының нәтиҗәләрен тикшерүләре. Сүзлек диктантлары – 7.<br>**Әлифбадан соңгы чор - Язу (5 сәгать)**<br>Балаларның язуларындагы график һәм каллиграфик хаталар төзәтелә, график күнекмәләр ныгытыла.Алгоритм буенча сүзләрдә язма хәрефләрнең һәм аларны тоташтыру сызыкларын язу технологиясен ныгыту. Язма һәм басма текстлардан сүз һәм җөмләләрне күчереп язу, әйтеп яздыру. Алфавитттагы хәрефләрнең урынын белү.<br>Аңлатмалы диктант – 1.<br>Грамматик биремле диктант – 1. | сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә эшләү.<br>**Авазлар һәм хәрефләр (16 сәгать)**<br>Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Авазларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, юлдан юлга күчерү.Яңгырау һәм саңгырау тартыклар, аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.**Йомгаклау диктанты.**<br>**Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту (7 сәгать)**<br>Татар теле дәресләрендә өйрәнгәннәрне ныгыту өчен, дәреслек ахырындагы сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. |

## 2класс

**Фонетика, грамматика, дөрес язу һәм сөйләм үстерү.**

Авазлар һәм хәрефләр

Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар һәм аларның хәрефләре. *Э* , *о* , *ө* , *е, ю* , *я* хәрефләрен сүздә дөрес язу кагыйдәләре. Сүзгә аваз-хәреф анализы

Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләре. Ъ, Ь хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре кергән сүзләр.Сүзлекләрдән кирәкле сүзләрне табу.

Иҗекләр. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Иҗек төзүдә сузык авазның әһәмияте. Язу юлы ахырына сыймаган сүзләрне бүлеп күчерүдә иҗекнең роле.

Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар. Парлы тартык авазлар. Парсыз тартык авазлар. Тартык авазларны хәрефләр белән белдерү. Сүздә *й, в, к, г* һәм *м, л, н, ң, х, һ* хәрефләрен язу һәм шул хәрефләр булган сүзләрне дөрес уку. Гади сүзләрдә янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләрен төшереп калдырмыйча язу *(мәхәббәт, эссе)* һ. б.

Калынлык, нечкәлек һәм аеру билгеләре буларак *ъ, ь* хәрефләрен куллану үрнәкләре белән таныштыру, шул хәрефләр булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Алфавит. Алфавитны белүнең әһәмияте. Татар алфавитында хәрефләрнең урнашу тәртибе, алар белдергән авазлар һәм хәреф исемнәре. Бирелгән сүзләрне, беренче хәрефләренә карап, алфавит тәртибендә язу. Укучылар өчен чыгарылган орфография сүзлегеннән файдалана белү.

Сүз

Сүз җирлеге. Предмет, билге, хәрәкәт һәм сүз. Авазлар һәм сүз. Иң кыска сүз *( у , и , ә )* .

Сүз тамыры. Сүзләрнең тамырлары белән таныштыру. Татарча сүзләрдә сүзнең тамыры сүз башында булуын, үзгәрмәвен, барлык кушымчаларның шуларга сингармонизм законына бәйле рәвештә ялганып килүен гамәли күзәтү *(эш: эшле, эшсез, эшлә, эшчән, эшлекле).*

Предметларны атаган һәм кем? нәрсә? сорауларына җавап биргән сүзләр. Предметларның билгеләрен белдергән һәм нинди? кайсы?'сорауларына җавап биргән сүзләр. Предметларның эшен, хәрәкәтен белдергән һәм нишли? нишләр? кебек сорауларга җавап биргән сүзләр. Шул сүзләрне, сораулар куеп, җөмлә эченнән таба белү.

Кеше исемнәрендә, фамилияләрдә, йорт хайваны кушаматларында, шәһәр, авыл, елга исемнәрендә баш хәреф.

Җөмлә

Сөйләмне җөмләләргә аеру. Җөмләдә сүзнең кем һәм нәрсә турында баруын күрсәткән һәм алар үтәгән эшне белдергән сүзләрне табу. Җөмлә төзүче баш кисәкләр (ия, хәбәр) белән таныштыру. Сораулар ярдәмендә җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү. Җөмләләрнең мәгънәви-интонацион үзенчәлекләрен күзәтү һәм җөмлә ахырында нокта, сорау, өндәү билгеләрен кую, җөмләләр төзү. Дөрестә укып тикшергән җөмләләрне ишетеп язу. Җөмләдәге ия белән хәбәрне сызыклар белән билгеләү.

Бәйләнешле сөйләм

Сөйләм. Сөйләмнең кешеләр тормышындагы әһәмияте. Өйтеп һәм язып аралашу үзенчәлекләрен гамәлдә күзәтү.

Текст. Тексттагы тәрәк сүзләрне аерып күрсәтү. Бер темага берләштерелгән аерым җөмләләрне текст белән чагыштыру. Текст темасын билгеләү. Текстны кисәкләргә бүлү. Зур булмаган текстка һәм текст кисәкләренә исем уйлап табу.

Изложение. Берәр әсәрне укып, кыскача аның эчтәлеген үз сүзләрең белән язу. Бирелгән сораулар буенча укытучы җитәкчелегендә инша язу. Сюжетлы рәсемнәргә карап, сораулар ярдәмендә мәгънәви эзлекле бәйләнгән җөмләләр төзү һәм шул җөмләләрне язып кую.

Сочинение. Укучыларның күмәк эшләре, уеннары, төрле шөгыльләре (чана шуу, җиләккә бару, бакчада эшләү һ. б.) турында үз ихтыярлары белән сөйләүләрен оештыру, телдән хикәяләү. Тора-бара кайберләрен бергәләп язып та кую.

Әдәпле сөйләшү. Кешеләр белән очрашканда, танышканда, каршы алганда, озатканда, саубуллашканда кулланылган сүзләр, рәхмәт әйтү, гафу үтенү һәм мөрәҗәгать итүләр. Уку елы дәвамында шул күнекмәләрне булдыру, шуңа гадәтләндерү өстендә өзлексез эшләү.

Матур язу

Язу гигиенасы кагыйдәләрен ныгыту: язганда дөрес утыру, дәфтәрне сул якка авыш итеп кую, ручканы дөрес тоту һ. б.

**3 класс**

| **Бүлек исеме** | **Эчтәлеккә таләпләр** |
|---|---|

| | |
|---|---|
| **Сөйләм эчтәлеге** | **Тыңлап аңлау.** Телдән аралашуның максатларын аңлау. Тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә төшенү, аның буенча сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу.<br>**Телдән сөйләм.** Тел берәмлекләрен сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә сайлый белү. Диалогик һәм монологик сөйләмдә катнашу, аерым темалар буенча әңгәмә кору. Фикерне телнең орфоэпик һәм интонацион нормаларын саклап җиткерү; сөйләм әдәбе үрнәкләрен дөрес куллану.<br>**Уку.** Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген аңлап, орфоэпик нормаларны саклап, җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап, йөгерек укый белү. Текстның темасын һәм төп фикерен билгели алу. Аның эчтәлегенә һәм төзелешенә бәя бирү.<br>**Язу.** Грамотага өйрәтү чорында хәрефләр, иҗекләр, сүзләр һәм җөмләләр язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә туры килә торган текстны әйтеп яздыру һәм күчереп язу. Укылган һәм тыңланган текстның эчтәлеген, тулы итеп яки сайлап, язмача бәян итү. Балалар өчен кызыклы булган темаларга сюжетлы картина, әдәби әсәр, видеоязма фрагментын карагач, күргәннәргә нигезләнеп һ.б.ш. типтагы кечкенә күләмле үз текстыңны төзү. |
| **Фонетика һәм орфоэпия** | Сузык һәм тартык авазларны аеру. Сүзләрдә басымлы һәм басымсыз сузык авазларны табу. Нечкә һәм калын тартык авазларны аеру, парлы һәм парсыз тартык авазларны билгеләү. Яңгырау авазларны аеру, аларның парларын билгеләү. Авазга өйрәнелгән күләмдә характеристика бирү: сузык-тартык; басымлы-басымсыз; калын-нечкә, яңгырау-саңгырау, парлы яки парсыз тартык. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Авазларның хәзерге әдәби тел нормаларына туры килгән әйтелеше. Сүзгә фонетик анализ элементлары. |
| **Графика** | Аваз һәм хәрефне аеру. Язуда **ъ** һәм **ь** хәрефләренкуллану. **Е – ѐ**, **ю**, **я** хәрефләре булган сүзләрдә аваз һәм хәреф бәйләнешен билгеләү. Сүзләр арасында буш урын калдыру, юлдан-юлга күчерү билгесе кую, кызыл юл кебек график чараларны куллану. Алфавиттагы хәрефләрнең исемен дөрес әйтү, аларның урнашу тәртибен белү. Сүзлекләр яки белешмәлекләр белән эшләгәндә, алфавиттан файдалана белү. |
| **Лексикологи я** | Сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бердәмлеге булуын аңлау. Мәгънәсе төгәллек таләп итә торган сүзләрне ачыклау. Сүзнең мәгънәсен текст буенча яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачып бирү. Бер һәм күп мәгънәле, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне табу. Сөйләмдә синоним һәм антонимнарның кулланылышына игътибар итү. |
| **Сүз төзелеше (морфемика)** | Тамырдаш сүзләр турында төшенчә булдыру. Тамырдаш сүзләрне бер сүзнең төрле формаларыннан аеру. Тамырдаш сүзләрне омонимнардан аеру. Сүзләрдә тамыр һәм кушымчаны аерып күрсәтү. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү. Тамырдаш сүзләрнең сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалуы. Сүз төзелешен тикшерү |

| | |
|---|---|
| | күнегүләрен үстерү. |
| **Морфология** | Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Ялгызлык исемнәрне таба белү. *Кем?Нәрсә?* сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәрнең сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше, аларның килешләрен билгеләү. Килеш сораулары. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау.<br>Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфатның сораулары. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатка морфологик анализ ясау.<br>Алмашлык. Алмашлык турында гомуми төшенчә. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнеше.<br>Фигыль. Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. *Нишли? Нишләде? Нишләр?* сорауларына җавап биргән фигыльләрне аеру. Фигыльнең зат-сан белән төрләнүе, төрле заман формалары (хәзерге, үткән, киләчәк заманнар). Фигыльнең барлык һәм юклыкта килүе. Фигыльләргә морфологик анализ ясау.<br>Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.Бәйлекләр. |
| **Синтаксис** | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Сүзтезмәдәге сүзләр һәм җөмлә кисәкләре арасында мәгънәви сораулар ярдәмендә бәйләнеш булдыру.<br>Теркәгечле (*һәм, ә, ләкин*) һәм теркәгечсез тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу һәм мөстәкыйль рәвештә төзү. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясе.<br>Гади һәм кушма җөмләләрне аеру. |
| **Орфография һәм пунктуация** | Укучыларда орфографик зирәклек тәрбияләү.<br>Дөрес язу кагыйдәләрен куллану:<br>– сузык аваз хәрефләрен дөрес язу кагыйдәләре;<br>– тартык аваз хәрефләрен дөрес язу;<br>– сүзне юлдан-юлга күчерү;<br>– җөмлә башындагы беренче сүзне һәм ялгызлык исемнәрне баш хәреф белән язу;<br>– калынлык (ъ) һәм нечкәлек (ь) билгеләрен дөрес язу; |

| | |
|---|---|
| | – һәмзә [ ’ ] авазын язуда белдерү;<br>– җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре кую;<br>– тиңдәш кисәкләр арасында өтер кую. |
| **Бәйләнешле сөйләм үстерү** | Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү). Татар телен йомшаграк белүче кешеләр белән аралашканда сөйләм әдәбе үзенчәлекләре.<br>Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.<br>Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.<br>Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.<br>Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.<br>Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.<br>Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.<br>Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.<br>Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б. |

**4класс**

**Авазлар һәм хәрефләр. Иҗек.**

Кабатлау. Авазлар һәм хәрефләр. Аларнын бүленеше. Сүзгә аваз-хәреф анализы.

**Сүз төзелеше**

Сүз ясалышы. Тамыр сүзләр, ясалма сүзләр, кушма һәм парлы сүзләр. Аларның ясалышы һәм дөрес язылышы, Рус теле аша кергән алынма кушма сүзләр. Сүз төзелешенә анализ ясау.

**Сүз. Сүз төркемнәре**

Сүзнең лексик мәгънәсе (гомуми төшенчә). Күп мәгънәле сүзләр. Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Синонимнар. Антонимнар. Искергән һәм яңа сүзләр (таныштыру).

**Исемнәрнең** берлектә һәм күплектә килеш белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы.

**Фигыль** төркемчәләре. Аның зат, сан белән төрләнеше. Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе. Текстта синоним һәм антоним фигыльләрне куллану.

**Сыйфат** дәрәҗәләре. Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы.

Сыйфатларның җөмләдәге роле (иярчен кисәкләр һәм хәбәр булып килүе). Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылуы. Антоним сыйфатлар, синоним сыйфатлар.

**Алмашлык**. Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше һәм дөрес язылышы. Аларның бәйлекләр белән килүе һәм дөрес язылышы, күләм, чама белдерүче сүзләрне алмаштырып килүе.

Алмашлыкларның җөмләдәге роле.

Текстта кабатланып килгән исемнәр урынына — алмашлык, алмашлыклар урынына исем куллану.

**Кисәкчә.** Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле — мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүләре.

Аларны аралашу ситуациясенә һәм сөйләм максатына туры китереп урынлы, төгәл куллану.

**Бәйлек.** Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр.

**Рәвеш.** Сөйләмдә актив кулланышлы рәвешләргә һәм аларның дөрес язылышына күзәтүләр оештыру.

**Җөмлә**

Җөмләнең баш һәм иярчең кисәкләре. Гади җөмлә, ике гади җөмләдән торган тезмә кушма җөмлә (таныштыру). Җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнеп килүе. Тиңдәш кисәкләр янында *һәм, ә, ләкин, әмма* теркәгечләре. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

**Сүзтезмә.** Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше.

**Текст. Бәйләнешле** сөйләм

Текст, аның темасы, төп фикере, бүлек башы, текстның кисәкләре, алар арасындагы һәм җөмләләр арасындагы бәйләнеш, укучыларның текст планы турындагы белемнәрен гомумиләштерү. Текстларның төрләре (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү). Текстта сурәтләү чаралары. Хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларның төзелеше. Текстларның эчтәлеген тулысынча һәм кыскартып сөйләү. Тел-дән рәсем, диафильм, кинофильм эпизодлары буенча хикәя төзү. Хикәя төзегәндә эпитет, метафора, җанландыру, чагыштыру куллану. Сино-ним фигыльләрдән, синоним сыйфатлардан файдалану. Фәннәр буенча телдән җавап бирүнең үзенчәлекләре (уку эшчәнлегенә бәйле сөйләм стиле).

**Матур язу** (һәр дәрестә)

Хәрефләрнең дөрес язылышын, аларның сүзләрдә рациональ тоташтырылуын узләштерү һәм камилләштерү.

Язу тизлеген үстерү. Ритмик салмак язу күнегүләре аша тиз язуга күчү. Укучыларның язуындагы графикага кагылышлы кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү.

**Язылышы истә калдырылырга тиешле сүзләр**

*Авыру, азмаз, ата-ана, ашхаш аңлый, әби-бабай. әверелә, әүвәл, балачак, бәет, бәла, берничә, борынгы, вакыйга,ватык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү,*

*җепшек, җиләк-җимеш, җиңел, зинһар, иелә, ихтирам, йомры, кадәр,каушый, кием-салым, кулъязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал*
*туар, махсус, мәйдан, мәкалә, мәрхәмәт, могҗиза,* ***моң****лы, мөстәкыйль, нәкъ, охшаш, очрак, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәвеш,рәссам, савыт- саба,*
*сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тәхет, тирә-як, төер,туп-туры, тылсымлы, тынгылык, харап, хыял, чүп-чар, чыдамлы, шагыйрь, шакката, шау-шу, шәкерт, шәфәкъ,шыңшый, шыпырт, эшчән, юеш, юньле, юучы, ява, яланаяк, ямьле, ямь-яшел, ять-яшь.*

**Тематик планлаштыру**

1 класс

| № | Тема | Сҽгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Ҽзерлек чоры | 10сҽг. |
| 2. | Ҽлифба чоры | 51сҽг. |
| 3. | Ҽлифбадан соңгы чор. | 5сҽг. |
| 4. | Җҿмлҽ . Җҿмлҽ ахырында тыныш билгелҽре | 2сҽг. |
| 5. | Сүзлҽр. | 3сҽг. |
| 6. | Телдҽн һҽм язма сҿйлҽм серлҽре. | 5сҽг. |
| 7. | Авазлар һҽм хҽрефлҽр. | 16сҽг. |
| 8. | Уку елында ҿйрҽнгҽннҽрне ныгыту. | 9сҽг. |
| | Барлыгы | 99 |

**2 класс**

| № | Тема | Сҽгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Фонетика һҽм орфоэпия | 20сҽг. |
| 2. | Графика | 4сҽг. |
| 3. | Сүз | 40сҽг. |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Җөмлә | 24сәг. |
| 5. | Бәйләнешле сөйләм | 14сәг. |
| | Барлыгы | 102 сәг |

**3класс**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Орфограмма | 11сәг. |
| 2. | Сүз.Телнең сүзлек байлыгы | 8сәг. |
| 3. | Сүз төзелеше.Сүз ясалышы. | 8сәг. |
| 4. | Сүз төркемнәре | 13сәг. |
| 5. | Фигыл | 18сәг. |
| 6. | Сыйфат | 9сәг. |
| 7. | Алмашлык | 5сәг |
| 8. | Кисәкчәләр | 4сәг |
| 9. | Бәйлекләр | 2сәг. |
| 10. | Җөмлә | 9сәг. |
| 11. | Сүзтезмә | 1сәг. |
| 12. | Бәйләнешле сөйләм | 10сәг. |
| 13. | Ел буена үткәннәрне кабатлау. | |
| | Барлыгы | 136 сәг |

**4 класс**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | 1-3нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 8сәг. |
| 2. | Сүзнең лексик мәгънәсе | 8сәг. |
| 3. | Сүз төзелеше. | 11сәг. |
| 4. | Исем | 8сәг. |
| 5. | Фигыл | 13сәг |
| 6. | Сыйфат | 7сәг. |
| 7. | Алмашлык | 6сәг. |
| 8. | Сан | 6сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Рәвеш | 5сәг. |
| 10. | Кисәкчәләр | 2сәг. |
| 11. | Бәйлекләр | 2сәг. |
| 12. | Җөмлә.Сүзтезмә. | 2сәг. |
| 13 | Ия һәм хәбәр | 2сәг. |
| 14. | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. | 1сәг. |
| 15. | Җөмләнең иярчен кисәкләре | 5сәг. |
| | Барлыгы | 102 сәг |

В данном документе пронумеровано,
Прошнуровано и скреплено печатью
_________________________ листов
Директор школы: ______________
З.А.Гайнуллин